СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная , д. 2а, д.НижниеАты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 2 йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

**Тел. (84366)507-35, факс (84366)507-35. E-mail: Sat .Ars@tatar.ru**

## Урта Аты авыл җирлеге советы карары

**«29 » ноябрь 2023 ел** **№ 115**

Урта Аты авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 августында кабул ителгән « Җир салымы турында» 71 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2022 елның 29 декабрендә кабул ителгән 87 номерлы карары редакциясендә)

2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Уставына таянып, Урта Аты авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Урта Аты авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 августындагы 71 номерлы « Җир салымы турындагы » карарына (2022 елның 29 декабрендә кабул ителгән 87 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның 2.4 нче пункт астындагы « һәм объектлар белән» сүзләрен «һәм (яки) объектлар белән»,«объектка туры килә торган җир участогына хокуклы өлеш» сүзләрен күчемсез милек объектына туры килә торган җир участогы өлешләре« һәм «һәм объектларга »сүзләрен »һәм (яки) объектларга сүзләре белән алыштырырга;

2. Әлеге карарның 1 пунктының гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми рәвештә бастырылганнан соң бер ай узгач кына үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Батталова